**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 13 август № 553

г. Казань

Муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{33}$, $39^{36}$ статьялары, «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 ел, 25 октябрь, ФЗ-137 нче Федераль закон, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында» 2009 ел, 28 декабрь, ФЗ-381 нче Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен (карарга теркәлә) расларга.
2. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру мәсьәләләрен регламентлаштыра торган муниципаль норматив хокукый актларын әлеге карарга туры китерүне тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карар стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру урыннарын бирү тәртибе федераль законнарда билгеләнгәнгә кадәр гамәлдә була дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков